РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 11

2019 елның 13 феврале

«Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 7нче номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә: Югары Чаллы авылында территориаль зоналарга төзәтмәләр кертү (1нче кушымта) һәм санитар-сак зонасыннан чыгару (2нче кушымта) өлешендә.

2. Әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында һәм Түбән Кама муниципаль районы һәм Кызыл Чапчак авыл җирлегенең рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

3. Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында (РФ ТП ФДМС) кертелгән үзгәрешләр белән Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
район Башлыгы урынбасары

Э.Р. Долотказина